

Мордовия Республикасы һәм Пенза олкәсе буенча Россельхознадзор идарәсенен ветеринария контроле бvлеге инспекторлары быел беренче тапкыр Зубово-Поляны районында хай ваннарнын котыру очрагы теркәлvе турында хәбәр итә . Бу райондагы Умет авылында яшәvче гражданиннын шәхси ярдәм че хужалыгы территориясеннән ките релгән толкенен котыру авыруына алган анализы, «Мордовия Республика ветеринария лабораториясе»нен лаборатория тикшеренvе нәтижәсендә, унай булган. Шуна Мордовия Республикасы Башлыгы Указы белән чикләv чаралары (карантин) билгеләнде, шулай ук әлеге торак пункт терри ториясендә терлекләр котыру авыруын локальләштерv һәм бетерv буенча чаралар планы расланды.
Котыру - хайваннар һәм кешенен полиоэнцефаломиелит билгеләре бе лән, абсолют vлем белән характерла на торган кискен вируслы авыруы. Ә котырунын табигый-чыганак инфекциясе булып кыргый хайваннар, бигрәк толкеләр тора. Котыру авыруы еш кына зарарланган тире ослеген яки лайлалы тышчаларны тешләгәндә яки озгәндә барлыкка килә. Авыру озакка сузылган яшерен (симптомсыз) чор белән характерлана һәм vзәк нерв системасынын (баш һәм арка мие, баш миенен каты тышчалары, менингеаль тышчалар) авыр зарарлануы белән бергә vрелеп бара. Әгәр хайван кешене тешләсә яки тырнаса, кичекмәстән яраны, царапиналарны һәм слюна эләккән барлык урыннарны, сабын эретмәсе белән 15 минуттан да ким булмаган кvләмдә юарга, аннан сон водород перекисе эретмәсе белән эшкәртергә кирәк. Яра краен 5 процентлы йод белән эшкәртелә. Шуннан сон момкин кадәр тизрәк яшәv урыны буенча травмпункттагы табиб-травматологка морәҗәгать итәргә кирәк; кирәк булганда ул профилактик прививкалар курсы билгеләячәк.
Һәрберебез “Кеше һәм хайваннар очен уртак булган йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы корәш” ветеринария кагый- дәләрен тогәл vтәргә тиеш. Шулай ук хайваннарнын котыру авыруларына каршы корәш буенча район станциясенә, авыл хужалыгы һәм йорт хайваннарын кыргый ерткычлар, этләр яки мәчеләр тешләгән очракларда, хайваннарнын котыру авыруына шикләнv турында кичекмәстән хәбәр итәргә; авыру яки тешләнгән хайваннарны ышанычлы изоляцияләргә кирәк.